| ГЛАВА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**16.11.2016** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 01-247** |

«2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты турында» Зеленодольск муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 28 статьясы һәм Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 15 статьясы Уставы нигезендә, ачык тыңлаулар уздыру юлы белән 2016 елга Зеленодольск муниципаль районы бюджеты проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен Зеленодольск муниципаль районында яшәүчеләрнең хокукларын үтәү максатларында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты турында» Зеленодольск муниципаль районы Советының гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән вакытларда карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.
2. Билгеләргә:

2.1. үткәрү датасы һәм вакыты - 2016 елның 6 декабрендә 16.00 сәгатьтә;

2.2. үткәрү вакыты 1 көн;

2.3. үткәрү урыны - Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 46 йорт, Горький исемендәге мәдәният, сәнгать һәм халык иҗаты үзәге;

2.4. фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелә торган адрес - Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорты, Зеленодольск муниципаль районы Советы, 111 нче кабинет

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына:

3.1.«2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты турында» Зеленодольск муниципаль районы Советының гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән вакытларда карар проекты буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

3.2. ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре буенча Зеленодольск муниципаль районы Советына ачык тыңлаулар беркетмәсен, ачык тыңлаулар тәкъдимнәрен, ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмәне, шулай ук эшләп бетерелгән (үзгәрешләр кертелгән очракта) 2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджеты проектын тапшырырга;

3.3. 2016 елның 10 декабренә кадәр Зеленодольск муниципаль районының 2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына бюджеты проекты буенча «Зеленодольская правда», «Яшел Үзән» газеталарында ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен бастырып чыгарырга.

4. 2016 елның 21 ноябренә кадәр әлеге карарны «Зеленодольская правда», «Яшел Үзән» газеталарында бастырып чыгарырга, шулай ук Зеленодольск муниципаль районының 2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына бюджеты проекты белән бергә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы сайтына (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтына (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә, Зеленодольск шәһәрендәге Горький исемендәге мәдәният, сәнгать һәм халык иҗаты үзәгендә (Ленин ур., 46 йорт, китапханәнең уку залы), «Зеленодольск муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУнең Ф. Шәфигуллин исемендәге 42 нче милли-туган якны өйрәнү китапханәсе – филиалында (М. Жуков ур., 7 нче йорт, китапханәнең уку залы) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Э.Р. Кадниковага йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы А.В. Тыгин**